# Чын дус

1.Чын дуслар була сирәк
Дуслыкны саклау кирәк
Чын дус – ул терәк, кыя,
Аңа бар сереӊ сыя.

Кушымта:
Бел дустыңның кадерен
Гел шатландыр күңелен
Дусны кирәк якларга,
Ышанычын якларга.

2.Ул сине яхшы белә
Уңыш-шатлыгың бүлә.
Килеп җитә ярдәмгә
Сиңа бәла килгәндә.